| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Шаршадинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Шаршады авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 Шаршады авылы № 44-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3, 4 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Шаршады авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге Советы к а р а р б и р д е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы теркәлгән нигезләмәне яңа редакциядә расларга.

2 Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 августында кабул ителгән 41-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын үткәрүгә әзерләнү тәртибе турында»гы Положениене раслау турында» карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Шаршады авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сове рәисе В.Г. БАГАУТДИНОВ

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге Советы
Карары белән расланган
16.11.2018 № 44-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Шаршады авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына кергән торак пунктларларда гражданнар җыеннары әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында положение

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Шаршады авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына кергән торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Положение “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль Законның 06.10.2003 № 131-ФЗ 25.1 маддәсенә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законына 28.07.2004 №45-ЗРТ нигезләнеп эшләнде.

**1. Гомуми положениеләр**

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм ирекле белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пункт территориясендә даими яшәүче, бу торак пунктта яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхси катнаша һәм бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены җирле әһәмияткә ия сорауларны хәл итү максатларында үткәрелә.

**Гражданнар җыены вәкаләтләре**

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге сораулар буенча үткәрелергә мөмкин:

торак пунктта җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләләре, әлеге торак пунктны башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертү;

муниципаль берәмлекнең сайлап куелган органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән башкарылса, чикләрне үзгәртү мәсьәләләре буенча, әлеге җирлекне үзгәртеп кору буенча;

муниципаль берәмлекнең сайлап куйган органы вәкаләтләрен гражданнар җыены башкарган җирлектә, әгәр җирлектә яшәүчеләр саны 100 кешедән артык икән, җирлекнең сайлап куйган органын оештыру, аның саны һәм вәкаләтләре срогы;

муниципаль берәмлекнең сайлап куйган органы вәкаләтләрен гражданнар җыены башкарган җирлектә гражданнарның үзара салымны кертү һәм аны файдалану мәсьәләләре буенча;

җирлек составына кергән торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә үзара салымны кертү һәм аны куллану мәсьәләләре буенча;

авылара территориядә урнашкан торак пунктта җирле үзидарәне оештыру һәм аны тормышка ашыру белән бәйле сораулар буенча халык инициативасын күтәреп чыгу максатларында;

авыл торак пунктында торак пункт старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләләре, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләләре буенча;

Россия Федерациясенең муниципаль хезмәт турындагы законнары белән каралган муниципаль хезмәт вазифасына конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатлар күрсәтү максатларында торак пунктта гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру тәэмин итү**

1.7. Җыен үткәрүне муниципаль берәмлек башлыгы тәэмин итә.

1.8. Җыен әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек казнасы акчасы хисабына башкарыла.

**2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе**

Гражданнар җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыены үткәрү инициативасы

- муниципаль берәмлек башлыгына;
- халык саны уннан да ким булмаган торак пунктта сайлау хокукына ия, гражданнар җыенында катнашу хокукы булган яшәүчеләргә.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләр инициативасы имзалар кәгазендә (кушымта №1) язылырга тиеш йә инициатив төркем җыелышы беркетмәсенә языла һәм анда күрсәтелә:

-гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләләр;
- тәкъдим ителгән гражданнар җыены үткәрү вакыты;
- җыенны чакыру инициативасын яклап чыккан гражданинның фамилия, исеме, атасының исеме, яшәү урыны адресы, имзасы һәм аны кую вакыты.

2.3. Җыен үткәрү инициативасын яклап чыгучыларның имзалар саны сайлау хокукы булган, торак пункт территориясендә даими яшәүче, шунда теркәлгән гражданнарның 5 процентын тәшкил итә, әмма ул 25 имзадан ким булмаска тиеш.

2.4. Имзалар кәгазе имза җыючы зат имзасы белән раслана, аның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, паспорт номеры, сериясе, адресы, датасы языла һәм муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

**Гражданнар җыены үткәрү турында карар кабул итү тәртибе**

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырылган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең сайлап куелган органы карары (кушымта №2) белән

билгеләнелә, ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы буенча-муниципаль берәмлек башлыгы карары (кушымта №3) белән барлык документлар кергәннән соң 30 көн дәвамында.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы йә муниципаль берәмлекнең сайлап куйган органы гражданнар җыены үткәрүне кире кага алмый.

2.7. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы чыгарга тиеш түгел. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләләрне шулай итеп формулаштырырга кирәк, ул күп мәгънә аңлатырга тиеш түгел, аңа бер төрле генә җавап бирерлек булсын.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карарны рәсми бастыру (халыкка җиткерү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнелә һәм муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә басыла (халыкка җиткерелә).

Мунципаль берәмлек башлыгы йә муниципаль берәмлекнең сайлап куйган органы карарларында гражданнар җыены үткәрү турында түбәндәгеләр күрсәтелә: җыенга чыгарылган мәсьәлә; җыенны үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – муниципаль берәмлек органының структур подразделениесе турында белешмә.

2.9. Гражданнар җыены әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы зат муниципаль берәмлек башлыгы йә муниципаль органының сайланган органы карары нигезендә торак пунктның сайлау хокукына ия яшәүчеләре исемлеген төзи; җыенга мәгълүмат материалларын әзерли; муниципаль берәмлек халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары йә башка ысуллар аша хәбәр итә. (кушымта №4)

Муниципаль берәмлекнең башкару-билгеләү органы гражданнар җыены үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыены үткәрү урыны һәм вакыты турында вакытында хәбәр ителә. Гражданнар җыены үткәрү урыны һәм вакытын билгеләү турындагы карар аны үткәргәнче ун көн алдан басылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

2.9.2. Гражданнар җыенында катнашучылар аны үткәрү көненә биш көн кала көн тәртибенә чыгарыла торган материаллар белән танышырга һәм аларның күчермәсен алырга хокуклы.

2.10. Положениега туры китереп гражданнар җыены үткәрү вакыты соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Аны күчерү турындагы карар билгеләнгән вакытка ун көн кала кабул ителергә тиеш.

**3. Гражданнар җыены үткәрү тәртибе**

3.1. Гражданнар җыенына килүчеләрне муниципаль берәмлек башлыгы вәкиле терки. Исемлектә аның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе, номеры языла.

3.2. Җыенга хәл итү тавышы булмаган башка гражданнар, әгәр җыенда алар эшчәнлегенә караган мәсьәләләр булса, предприятие, учреждение

җитәкчеләре дә, матбугат һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнаша ала.

3.3. Әгәр торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлек китсә, муниципаль берәмлек башлыгы торак пунктта яшәүчене терки һәм аны җыенга кертә.

3.4. Исемлектәге язуларда төгәлсезлекләрне ачыкларга шәхесне раслаучы документ (паспорт, чит ил гражданины паспорты, вакытлыча яшәүгә рөхсәт) нигез булып тора.

3.5. Гражданнар җыены торак пунктта яшәүче, сайлау хокукына ия булганнарның яртысыннан артыгы катнашса үткәрелә. Кворум җитмәсә җыен үткәрүнең яңа датасын муниципаль берәмлек башлыгы билгели. Бу очракта ул башта билгеләнгән көннән соң ун көннән соң үткәрелә.

3.6. Җыенда тавыш бирү ачык йә ябык булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турындагы карар җыен тарафыннан кабул ителә.

3.7. Ябык тавыш бирү булганда гражданинга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (№5 кушымта).

3.8. Җыенда муниципаль берәмлек башлыгы йә ачык тавыш бирү юлы белән расланган башка зат рәислек итәргә мөмкин. Рәислек итүчене җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.9. Җыен секретарьне һәм счет комиссиясен сайлый. Счет комиссиясе саны ике кешедән артык булмаска тиеш. Җыенның көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, җыенда катнашучы гражданнар кертә ала. Көн тәртибенә җыен чакыру инициаторлары керткән мәсьәләләрне кертү мәҗбүри. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар җыенда катнашучыларның яртысыннан ким булмаганы тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала.

3.10. Җыенны рәислек итүче ача. Ул җыенны үткәрүне оештыра, тәртип саклый, счет комиссиясе эшен координацияли, чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирү тәртибен тәэмин итә.

3.11. Җыенда секретарь беркетмә алып бара, анда җыен үткәрү вакыты, урыны, торак пунктта яшәүчеләр саны, тавыш бирүгә хокуклылар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгыш ясаучылар чыгышларының кыскача эчтәлеге, тавыш бирүчеләр саны языла.

3.12. Беркетмә рәислек итүче һәм секретарь тарафыннан имзалана, муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгәннәр исемлеге теркәлә.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Җыен карары анда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокук карары дип санала, аларны муниципаль берәмлек башлыгы имзалый, алар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрына кертелә. (№7,8 кушымта).Муниципаль норматив хокукый актлар кабул ителгән (басылган)

көннән соң 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан вәкаләтле органга җибәрелә. Муниципаль норматив хокукый актлар белән бер үк вакытта муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) чыганаклары һәм даталары турында мәгълүматлар җибәрелә. Муниципаль норматив хокукый актларны 10 көнлек вакыт узганнан соң рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) очрагында, рәсми бастырып чыгару чыганаклары һәм даталары турында мәгълүматлар муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан рәсми басылып чыккан көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле органга җибәрелә.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм вазифаи затлар карарларны үтәүне тәэмин итә.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итеп үзгәртелергә йә кире алынырга мөмкин. Суд карары белән гамәлгә яраксыз дип саналырга мөмкин.

4.5. Җыенда кабул ителгән карар рәсми төстә басылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

4.6. Әгәр җыенда кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен өстәмә муниципаль хокук акты кабул итәргә кирәк икән, карар үз көченә кергәннән соң 15 көн дәвамында әлеге актны әзерләү һәм кабул итү срогын билгеләргә кирәк. Бу срок өч айдан артмаска тиеш.

**Гражданнар җыены карарларын үтәү**

4.7. Җыенда кабул ителгән карарларны торак пункт территориясендә үтәү мәҗбүри. Алар дәүләт власте тарафыннан расланырга тиеш түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү закон ингезендә җаваплылыкка китерә.

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

# ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

Без, түбәндә имза куючылар, инициативаны хуплыйбыз _______________ __________________________________гражданнар җыенын (гражданнар җыенын үткәрү вакытын) торак пунктта ________________ Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегендә түбәндәге мәсьәлә белән ___________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

| №№ | Фамилия, исем, атасының исеме | Туган елы | Яшәү урыны | Паспортның йә аны алыштыручы башка документның сериясе, номеры | Имза кую вакыты | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм ___________________________________________
(Имза җыючының Ф.И.О., туган елы,
________________________________________________________________________
яшәү урыны, паспорт йә аны алыштыручы документның сериясе, номеры)

________________
(имза, дата)

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

| | |
|---|---|
| **СОВЕТ<br>Шаршадинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Шаршады авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

_____________ Шаршады авылы № _______

Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегенең _________ торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче ФЗның 06.10.2003 № ФЗ-131 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Законның 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге Уставына тәңгәл китереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге Советы к а р а р б и р д е:

1. Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегенең __________ торак пунктында ________________мәсьәлә буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Җыенга чыгарылган мәсьәләне расларга:

“Сез ризамы ____________________________________________________
______________________________________________________________

4. Әлеге карарны Шаршады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Әгерҗе муниципаль районы сайтына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы аша халыкка җиткерергә.

5. Карар басылганнан көннән көченә керә.

6. Карарны үтәүгә контрольне үз өстемә калдырам.

Совет рәисе В.Х. БАГАУТДИНОВ

Кушымта № 3
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАРШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАРШАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_____________ Шаршады авылы № ______

Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге ________________торак пунктында ________________ мәсьәлә буенча гражданнар җыены турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче ФЗның 06.10.2003 № ФЗ-131 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге Уставына тәңгәл китереп, Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы к а р а р ч ы г а р д ы:

1. ________________________________________мәсьәлә буенча гражданнар җыенын “____”______________ 20___ билгеләргә.

2. Бу карар кабул ителгәннән соң ______ көн дәвамында мәгълүмат стендларына, рәсми сайтка кую юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Карар басылган көннән соң үз көченә керә.

В.Х. БАГАУТДИНОВ

Кушымта № 4
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

_______________________________________ ___________________________
(муниципаль район исеме) (җирлек исеме)

______________________________ сайлау хокукы булган яшәүчеләр
(торак пункт исеме)

ИСЕМЛЕГЕ
“____” ____________ 20___ ел

| №№ | Фамилия, исем, атасының исеме | Туган елы | Яшәү урыны | Паспортның йә аны алыштыручы башка документның сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче ___________ ____________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены секретаре ___________ ____________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Кушымта № 5
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге составына кергән _____________торак пунктта ___________________мәсьәлә буенча яшерен тавыш бирү

БЮЛЛЕТЕНЕ

| | |
|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган мәсьәләнең эчтәлеге | “Әйе” |
| | “Юк” |
| | “Тавыш бирүдән тыелдым” |

Кушымта № 6
Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

“____” ____________ 20__ ел №_____

________________________
(торак пункт исеме)

Катнаштылар ____________________________________________________________
торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми саны, сайлау хокукы булган гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ______________________________________
(Ф.И.О.)
Гражданнар җыены секретаре ______________________________________
(Ф.И.О.)

## КӨН ТӘРТИБЕ:

1.

2.

**Беренче мәсьәлә буенча тыңланды:**
_______________________________________________
(Ф.И.О.)
(чыгышның кыскача язмасы йә доклад беркетелә)

**Чыгыш ясадылар**: 1. ______________________________________________________
(Ф.И.О.)
(чыгышның кыскача язмасы йә чыгыш тексты беркетелә)

**Карар чыгарылды:** (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү йомгаклары: “Әйе” _______кеше
“Юк” _______кеше
“Тавыш бирүдән тыелдым” ______кеше

Карар __________________
(кабул ителде, ителмәде)

**Икенче  мәсьәлә буенча тыңланды:**

_____________________________________________

(Ф.И.О.)

(чыгышның кыскача язмасы йә доклад беркетелә)

**Чыгыш ясадылар**: 1. ________________________________________________

(Ф.И.О.)

(чыгышның кыскача язмасы йә чыгыш тексты беркетелә)

**Карар чыгарылды:** (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү йомгаклары: “Әйе” _______кеше
“Юк” _______кеше
“Тавыш бирүдән тыелдым” ______кеше

Карар _________________

(кабул ителде, ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ _______________________

(имза) (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены секретаре __________ _______________________

(имза) (имзаны расшифровкалау)

Кушымта № 7
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

# К А Р А Р
## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге составына кергән ________________торак пунктта гражданнар җыены йомгаклары турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы ФЗның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә тәңгәл китереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге составына кергән _____________ торак пунктта ___________________________________________ мәсьәлә буенча “___” __________20___ елда үткәрелгән гражданнар җыены йомгаклары белән беркетмә төзелде һәм алынган средстволарны чыгымнарга конкрет юнәлтелде: 1).....; 2)...... .

Гражданнар җыены йомгаклары турында беркетмәгә тәңгәл китереп:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган ___________ катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашты _________ кеше.

Тавыш бирү йомгаклары буенча катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясенә ___________ җыенда катнашучы;

“Юк” позициясенә ___________ катнашучы тавыш бирде.

Нәтиҗәдә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге ________________ торак пунктындагы гражданнар җыенын үтте, җыен йомгакларын гамәлгә яраклы дип билгеләргә.

2.______________мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге гражданнар җыены йомгакларын халыкка җиткерергә (халыкка җиткерү ысулын күрсәтергә).

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ___________ _________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе ___________ _________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Кушымта № 8
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге торак пунктларында
гражданнар җыеннары әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Положениега

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегенең _________________торак пунктында

“____” _____________ 20__ ел № _____

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы ФЗның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә тәңгәл китереп, ________________________ гражданнар
(торак пункт исеме)

җыены к а р а р ч ы г а р д ы:

1.

2.

3.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ___________ _________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе ___________ _________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)